
Кем ул
Кыш бабай?



Ул озын сакаллы һәм итек кигән әйбәт бабай. Кыш бабай узенең тылсымлы капчыгында бөтен кешегә дә бүләкләр алып килә. Ләкин син беләсеңме,ул каян килгән,кая яши?



Элегрәк безнең Кыш бабайны Трескун Бабай дип йөрткәннәр. Ул озын сакаллы бәләкәй кырыс карт булган.
Кыш бабайның хатыны  усал Кыш карчык Һәм тагын аның бик матур оныгы –Кар кызы булган.



**Кар кызы бик матур һәм ягымлы кыз. Ул кар һәм суык ярата,ә кояш нурларыннан эри. Балалар бәйрәмнәренә кар кызы бик шатланып килә,алар белән чыршы тирәли җырлар җырлап әйләнә.**

Кыш бабай үзенең резиденциясендә яши. Ул Великий Устюгта урнашкан (Вологодский өлкәсе). Әгәр сез хат язсагыз һәм «Вологодский өлкәсе, Великий Устюг шәһәре, Кыш бабай резиденциясе» адресы буенча җибәрсәгез, ул һичшиксез аңа барып җитәр.



Кыш бабайны бары тик кыш көне генә очратырга мөмкин. Ләкин аны ел буе ял итә дип уйларга кирәкми. Юк,ул узенең өендә эшли. Нәрсәләр эшли соң ул?





Кыш бабайның өендә остаханә бар.Ул анда яңа ел бүләкләре ясый:эретә,ябыштыра, буйый,лаклый ,агачтан әйберләр ясый…





**Кыш бабай – тәрәзәгә рәсем ясау остасы. Кышын төннәр буе ул буяусыз,кисточкасыз ,узенең бозлы сулышы белән,картиналар ясый.Ә аннары  безнең өйләрнең һәм машиналарның тәрәзәләрендә  кургәзмәләр оештыра.**

**Кыш бабай фәнни экспериментлар да ярата.Ул еш кына  яңа төрле төзелештәге кар бөртекләре уйлап таба. Учыңны кар яуганда куеп тор һәм аннары әйбәтләп кара.Син күрерсең,Кыш бабай ясаган һәр кар бөртеге кабатланмас һәм камил.**



**Кыш бабай- бөек  тылсымчы. Аның тылсымлы көзгесе бар. Кыш бабай һәр иртә аңа карый һәм шуңа да картаймый. Ә бит ул инде 2000 яшьтән узган !**



Туган көнен Кыш бабай  18 ноябрьдә үткәрә - бу датаны балалар аңа үзләре уйлап тапканнар, чөнки нәкъ  18 ноябрьдә  Великий Устюгта чын кыш җитә,суыклар башланып китә.



Һәм әлбәттә ,Кыш бабайның иң мөһим эшләренең берсе-Яңа ел җиткәнче барлык хатларны да укып бетерү.Ел саен Кыш бабайга биш йөз меңгә якын хат килә!



Балаларга үзләре сораган бүләкне алып килү өчен Кыш бабай һәр хатны игътибар белән укый .



**Хәзерге заман Кыш бабае-ул шат күңелле һәм әйбәт карт.Аны озын ак сакалы,кызыл шапкасы, тылсымлы таягы һәм бүләкләр белән тулы зур капчыгыннан танып була.**


Великий Устюг -
родина Деда Мороза
ДЕД МОРОЗ ВЕЛИКИЙ УСТЮГ
тәмам